ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19 май 2026 ел № 561

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларының яңа редакциядә раслау турында» 2021 елның 27 декабрендәге 1370 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре» МКУ муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларының яңа редакциядә раслау турында» 2021 елның 27 декабрендәге 1370 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегеннән гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында Карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

1.1. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.».

1.2. 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында

урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУсы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин